**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча 6 нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**

**3 нче  сыйныфының татар төркемендә уздырылган дәрес планы**

**Тема:  Р.Вәлиева “Туган көндә”**

Укытучы:

татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Шафигуллина Зиля Гилмулловна

Максат:”Туган көндә “хикәясе белән таныштыру .Сүз байлыгын арттыру,сөйләм телен үстерү. Укучыларда эти –әнигә, әби-бабайларга,өлкәннәргә карата хөрмәт һәм ярату хисләре тәрбияләү.

Җиһазлау: Р.Х.Ягъфәрова. Уку китабы 3 сыйныф,рәсемнәр,компьютер,проектор,Р.Вәлиева китапларыннан күргәзмә, җөмләләр язылган карточкалар

Дәрес барышы:

1.Оештыру.Актуальләштерү.

-Исәнмесез,укучылар.Хәерле көн!

-Бүген сыйныфта кем дежур?Атнаның ничәнче көне?Бүген көн нинди?Җил исәме?Кар явамы?Класста барлык укучы да бармы?

-Өйгә эш итеп нәрсә бирелгән иде?(Ш.Галиевның “Авылча,бабайча ял” шигырен сәнгатьле укырга

өйрәнергә).

-Бик яхшы укучылар.Дәү этине икенче төрле ничек атыйбыз?

2.Төп өлеш.

а)-Укучылар,сез бәйрәмнәр уздырырга яратасызмы?

-Сезгә нинди бәйрәмнәр ошый?

-Сез аларга ничек әзерләнәсез?

б)-Ә бүген без сезнең белән Р.Вәлиеваның”Туган көндә “хикәясен укырбыз.(Берничә укучы белән сөйләшеп алу)

-Синең туган көнең кайчан?

-Сезгә кемнәр килде?

-Алар килешкә сез ничек әзерләндегез?

-Ул көнне сезгә күңелле булдымы?

В)Сүзлек эше уздыру (проектор аша тактада күрсәтелә).

Аңышмыйчарак-аңлап бетермичә

Пөхтә-җыйнак,чиста.

Физкультминутка.(“Зинһар өчен”уены уйнатыла)

3.Дәреслек белән эш.88-89 нчы битләр.

1.Укытучының үрнәк укуы.

2.Сорауга җавап табу.

-Фәридә сезгә ошадымы?Ул нинди кыз?Аннан үрнәк алырга ярыймы?

3.Укучылар эчтән укып чыгалар.

4.Чылбырлап уку.

4.Дәфтәрләрдә эш.

а)-Фәридәләр бәйрәмгә ничек әзерләнгәннәр?(Шул җөмләләрне табып язу).

б)-90 нчы биттән әйтемнәрне күчереп язу,мәгънәләрен ачыклау.

Физкультминутка.(Ак калач).

5.Сораулар буенча эш уздыру. (телдән)90 нчы бит.

6.Карточкалар белән эш.

-Хәзер мин сезгә карточкалар таратам.Анда җөмләләрнең башы язылган,ә сез дәреслектән ахырын табып укыйсыз.

7.Интерактив тактада эш.

-Укучылар тактада җөмләләр язылган.Әгәр җөмлә дөрес булса,шул килеш калдырасыз,текст эчтәлегенә туры килмәсә,сызасыз.(Укучылар чиратлап интерактив тактада түбәндәге җөмләләр буенча эшлиләр).

1.Иртәгә Фәридәнең туган көне.

2.Өйләре дз искиткеч матур.

3.Фәридә бик шатлана.

4.Тиздән дуслары килә.

5.Әби дә залга чыксын.

6.Әнисе  Фәридәне мактады.

7.Дусларыңа шалтыратма.

8.Йомгаклау.

-Дәрес ошадымы сезгә?

-Фәридә кебек булырга ярыймы?

-Укучылар,дәү әниләр турында шигырьләр,җырлар да күп.(Китаплар күргәзмәсе күрсәтелә)Укытучы Р.Вәлиеваның “Дәү әнигә барабыз”дигән шигырьләр җыентыгын күрсәтә.Алдагы класстан тыш  уку дәресләрендә укыячаклары турында әйтә.

Өйгә эшкә укучыларның әбиләре турында хикәя сөйләргә бирелә.Һәр балага билге куела.